Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

31 октябрь 2023 ел № 39/2

КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының 2016 елның 10 ноябрендәге «Җир салымын түләүнең ставкаларын, тәртибен һәм срокларын гамәлгә кертү, билгеләү турында» 24/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында»гы 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль законның 2 статьясындагы 113 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының 2016 елның 10 ноябрендәге «Җир салымын түләүнең ставкаларын, тәртибен һәм срокларын гамәлгә кертү, билгеләү турында» 24/1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 пунктның 1.1 пунктчасындагы 3 абзацында «һәм объектлары» сүзләрен «һәм (яисә) объектлары» сүзләренә алмаштырырга, «объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлеш» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлегенең бер өлеше» сүзләренә, «һәм объектларга» сүзләрен «һәм (яисә) объектларга» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең халык күпләп йөри торган урыннарында махсус мәгълүмат стендларында яисә Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре порталында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан җир салымы түләү һәм җир салымы буенча аванс түләүләрне түләү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә;

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, хокук тәртибе һәм депутатлык эшчәнлеге мәсьәләсе буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Чистай муниципаль районының
Татар Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы ____________________ Р.Р.Гарифуллин
(имза)